| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

**09.01.2014 ел.** **№1-п**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30

декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы указларын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга (кушымтада бирелә).

2. Билгеләргә:

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин дәүләт граждан хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) ризалыгы белән, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфалар биләргә һәм (яки) бер ай дәвамында граждани-хокукый шартнамә (граждани-хокукый шартнамәләр) шартларында йөз мең сумнан артык бәягә әлеге оешмада эшләр башкарырга (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтергә) хокуклы, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса;

Комиссия граждани-хокукый шартнамә шартларында гражданлык-хокукый шартнамә шартларында әлеге оешмада эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) карата хезмәт шартнамәсе шартларында әлеге мөрәҗәгатьне Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә биләүгә ризалык бирү турында гражданинның язма мөрәҗәгатен карарга һәм кабул ителгән карар турында гражданинга бер эш көне эчендә язма хәбәр җибәрергә һәм аңа өч эш көне эчендә телдән хәбәр итәргә;

Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданин дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында әлеге Боерыкның 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән хезмәт шартнамәләрен яки эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турында граждани-хокукый шартнамәләр төзегән вакытта эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр тапшырырга тиеш;

дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданин тарафыннан югарыда күрсәтелгән Исемлек нигезендә, әлеге боерыкның 2 пунктының дүртенче абзацында каралган таләпне дәүләт хезмәтеннән эштән чыгарганнан соң үтәмәү әлеге гражданин белән төзелгән әлеге Боерыкның 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждани-хокукый шартнамәне туктатуга китерә;

Исемлек нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданин белән, ул дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә, әлеге Боерыкның 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждани-хокукый шартнамә төзегәндә, эш бирүче ун көн эчендә дәүләт хезмәткәренең яллаучысына (эш бирүчесенә) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә мондый шартнамә төзү турында хәбәр итәргә тиеш;

эш бирүче тарафыннан әлеге Боерыкның 2 пунктының алтынчы абзацында билгеләнгән бурычны үтәмәү хокук бозу булып санала һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка китерә;

әлеге Боерыкның 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданинның хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфа биләвенә һәм (яки) граждани-хокукый шартнамә (алга таба – граждани-хокукый шартнамәләр) шартларында әлеге оешмада эшләр башкаруына (хезмәтләр күрсәтүенә) карата федераль каралган очракларда тыюны үтәвен, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре дәүләт хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, һәм эшкә алучының мондый гражданин белән хезмәт шартнамәсен төзү шартларын яки граждани-хокукый шартнамә төзү шартларын үтәвен тикшерү Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә әлеге Боерыкны дәүләт граждан хезмәткәрләренә кул куйдыртып җиткерергә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К.Сәлимгәрәев) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә әлеге Боерык белән расланган вазыйфалар исемлеген расланган көннән башлап өч көн эчендә тапшырырга, ә алга таба аларга үзгәрешләр керткәндә, үзгәрешләр үзгәргәннән соң бер атна эчендә анықланган исемлекләрне тапшырырга.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр
А.Г.СИДОРОВ

1 нче кушымта

Татарстан Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2014 елның 9 гыйнварындагы
1-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеме:

министрның беренче урынбасары,

министр урынбасары,

министр урынбасары,

министр урынбасары.

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркеме:

эшләр идарәчесе,

икътисад һәм инвестиция эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе,

мәгълүмати-аналитик эшчәнлек идарәсе җитәкчесе,

Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу идарәсе җитәкчесе,

Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе җитәкчесе,

Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе,

Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе,

финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе,

хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе,

Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе җитәкчесе,

Үзәк территориаль идарә җитәкчесе,

Төньяк территориаль идарә җитәкчесе,

Идел аръягы территориаль идарәсе җитәкчесе,

Идел-Кама территориаль идарәсе җитәкчесе,

Кама буе территориаль идарәсе җитәкчесе,

Кама аръягы территориаль идарәсе җитәкчесе,

Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарә җитәкчесе,

Ык буе территориаль идарәсе җитәкчесе.

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеме:

министр ярдәмчесе,

финанс контроле, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары,

әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлеге башлыгы,

инвестиция программаларын үтәү бүлеге җитәкчесе,

дәүләт заказы, конкурс сатулары бүлеге җитәкчесе,

мәгълүмати системаларын үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге җитәкчесе,

дәүләт экология экспертизасы бүлеге җитәкчесе,

әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлеге җитәкчесе,

атмосфера һавасын саклау бүлеге җитәкчесе,

су объектларын саклау бүлеге җитәкчесе,

җир ресурсларын саклау бүлеге җитәкчесе,

житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү бүлеге җитәкчесе,

углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе,

каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе,

гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе,

гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе урынбасары,

җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе,

мәгълүмати геологик ресурслар һәм геология тирәлеген мониторинглау бүлеге җитәкчесе,

административ бүлек җитәкчесе,

җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү секторы мөдире,

Үзәк территориаль идарә җитәкчесе урынбасары – 2 вазыйфа,

Кама яны территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары,

Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе җитәкчесе урынбасары,

әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

инвестицион программаларны үтәү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 вазыйфа,

дәүләт экология экспертизасы бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлегенең әйдәп баручы белгече – 2 вазыйфа,

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 вазыйфа,

атмосфера һавасын саклау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

су объектларын саклау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

җир ресурсларын саклау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

углеводород чималы геологиясе бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече,

гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе,

җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 вазыйфа,

җир асты байлыкларыннан файдалану үсеше секторының әйдәп баручы киңәшчесе – 2 вазыйфа,

административ бүлекнең әйдәп баручы белгече.

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән төркеме:

Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 2 разрядлы өлкән белгече – 3

вазыйфа,

Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 3 нче разрядлы өлкән белгече,

Үзәк территориаль идарәнең 2 разрядлы өлкән белгече – 3 вазыйфа,

Үзәк территориаль идарәнең 3 разрядлы өлкән белгече – 4 вазыйфа,

Төньяк территориаль идарәнең 2 разрядлы өлкән белгече,

Идел Аръягы территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Идел Аръягы территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече,

Идел-Кама территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече,

Идел-Кама территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Кама яны территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече – 3 вазыйфа,

Кама яны территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Кама Аръягы территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече – 3 вазыйфа,

Кама Аръягы территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече – 2 вазыйфа,

Ык буе территориаль идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече,

Ык буе территориаль идарәсенең 3 разрядлы өлкән белгече.

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кече төркеме:

Үзәк территориаль идарәнең 1 разрядлы белгече – 2 вазыйфа,

Төньяк территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече – 2 вазыйфа,

Кама яны территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече – 2 вазыйфа,

Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече – 3 вазыйфа,

Кама Аръягы территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече,

Ык буе территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече,

Идел-Кама территориаль идарәсенең 1 разрядлы белгече – 2 вазыйфа.

Барлыгы 112 урын, шуларның:

- үзәк аппаратта 52 вазыйфа;
- территориаль идарәләрдә 60 вазыйфа.